СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2018 ел г.Мензелинск №4

**Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары отчеты турында**

Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2018 елда федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру, шулай ук 2019 елга планнар турында» гы докладын тыңлаганнан һәм карап, фикер алышканнан соң,

Минзәлә муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2018 елда федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру турында» хисабын расларга һәм район халкына җиткерергә.
2. Минзәлә муниципаль районы Советы аппаратына сессия барышында әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.
3. Башкарма комитетка Минзәлә муниципаль районы Советы каравына искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләүне һәм кертүне йөкләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советы рәисе урынбасары К. Р. Нәҗмиевкә һәм район Советының төзелеш, газ кертү, электр белән тәэмин итү, элемтә, транспорт һәм юллар буенча даими комиссиясе рәисе Н.С.Секуновка йөкләргә.

Минзәлә
муниципаль район башлыгы
Совет Рәисе

А. Ф. Сәлахов